КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 февраль г.Казань № 79

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 12 октябрь, 715 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 12 октябрь, 715 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 июль, 603 нче, 2010 ел, 1 октябрь, 779 нчы, 2011 ел, 13 май, 382 нче, 2012 ел, 8 июнь, 494 нчең, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2012 ел, 3 ноябрь, 948 нче, 2013 ел, 8 апрель, 239 нчы, 2014 ел, 9 август, 599 нчы, 2015 ел, 20 ноябрь, 884 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.2[1] һәм 1.2[2] пунктлар өстәргә:

«1.2[1]. Гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы конкурс яисә аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә, моңа «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган очраклар керми.

1.2[2]. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы конкурс яисә аукцион үткәрмичә түбәндәге максатлар өчен бирелә:

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану;

ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, әлеге ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү;

җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, разведкалау, җир асты суларын чыгару яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны разведкалау һәм чыгару.

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән күрсәтелгән эшләрне башкаруга, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару;

эчәр сулар белән тәэмин итү яисә коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурс яисә аукцион уздыру турында (алга таба - конкурс яисә аукцион), конкурс яисә аукцион комиссиясенең составы һәм эш тәртибе турында карарлар кабул итү һәм җир асты байлыкларының һәр кишәрлегенә яисә җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата мондый конкурслар һәм аукционнар үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2.1 пунктта «җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга аукцион (алга таба - аукцион)» сүзләрен «конкурс яисә аукцион» сүзләренә, «форма буенча аукцион уздырмыйча» сүзләрен «форма буенча конкурс яисә аукцион уздырмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктының беренче һәм икенче абзацларында «аукцион» сүзен «конкурс яисә аукцион» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктының беренче һәм икенче абзацларында «аукцион» сүзен «конкурс яисә аукцион» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктта:

1 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктчаның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктчаның икенче абзацында «бүлү балансы» сүзләрен «тапшыру акты» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктта «аукцион» сүзен «конкурс яисә аукцион» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин